

Темников районында һәйкәлләрне ремонтлау эшен башлаганнар. Шулай, 9нчы апрель конне Тархан авылында Боек Ватан сугышы батырларына багышланган һәйкәл янында эш кайный башлый. Кайчандыр Мәнгелек ут та яна иде һәйкәл янында, ә вакыт узу белән тузган бу корылма. “Газпром газораспределение Саранск” ачык акционерлар оешмасы эшчеләре тәвәккәлләп ремонтка тотынганнар. Жир асты корылмасы сузганнар, янгын урынын урнаштырганнар. Авыр, әмма кирәкле корылманы, авыл халкынын яхшылыкка ышанычын арттырып, урнаштырганнар. Газ белән сак эшләv нормалары белән бергә, хезмәткәрләр эпидемиологик саклылыкны да саклаганнар: барысы да маскалардан һәм перчаткалардан булдылар.
Газовщиклар бригадасы хезмәт кәрләре барлык район халкына бу авыр чорда кулны-кулга куеп эшсез коронавирус дип тормыйча, ветераннар турында онытмыйча, Жинvнен 75-еллыгын каршыларга әзерлек эшләрен башкарырга яхшы мисал булды. Тархан һәм Ишейка авыллары һәйкәлләрен ремонтлау буенча эш әле кvп, әмма мондый хезмәткәрләр булган очракта, Темников районы халкы Боек Ватан сугышы Жинvенә 75 ел тулуны лаеклы каршы алачаклар.